РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ АРТАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422069, Республика Татарстан, Сабинский район,
д.Два поля Арташ, ул. Тукая, 61
тел. (84362) 44-7-15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АРТАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422069, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Ике басу Арташ авылы, Тукай урамы, 61 йорт
тел. (84362) 44-7-15

e-mail: Art.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
18.02.2022

КАРАР
№3

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Советының 2021 нче елның 8 нче ноябрендә кабул ителгән 22 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәгә (алга таба – нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1.Нигезләмәнең 3 нче кушымтасын әлеге кararга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru

Арташ авыл
җирлеге башлыгы

А.Р.Әгъләмҗанов

Кушымта
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Советының 18.02.2022 ел №3 карарына

Кушымта № 3
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге чикләрендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

1. Муниципаль торак контроленең төп күрсәткечләре

1 нче таблица

| Төп күрсәткечләр | Максатчан күрсәткечләр |
|---|---|
| Торак законнарын бозу очраклары ачыкланган санның бетерелгән проценты | 70% |
| Чираттагы календарь елына планлы контроль чаралар үткәрү планын үтәү проценты | 100% |
| Муниципаль контроль органы һәм (яки) аның вазыйфаи затының контроль чаралар үткәргәндә гамәлләренә (гамәл кылмавына) нигезләнгән шикаятьләрнең проценты | 0% |
| Контроль чаралар нәтиҗәләренең бетерелгән проценты | 0% |
| Административ йогынты чаралары күрелмәгән нәтиҗәле контроль чаралар проценты | 5% |
| Муниципаль контроль органы материаллары буенча административ җәза билгеләү турында суд карарлары проценты | 95% |
| Административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча суд тәртибендә юкка чыгарылган карарларның муниципаль контроль органы тарафыннан чыгарылган карарларның гомуми саныннан проценты | 0% |

2. Чаралар үткәрү параметрларын характерлаучы индикатив күрсәткечләр

2.1. Муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда түбәндәге индикатив күрсәткечләр билгеләнә;

1) хисап чорында үткәрелгән планнан тыш тикшерү чаралары саны;

2) контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга туры килү-килмәүне ачыклау яисә хисап чорында контроль объектының мондый параметрлардан читләшүен ачыклау нигезендә хисап чорында үткәрелгән планнан тыш тикшерү чаралары саны;

3) хисап чорында үткәрелгән үзара хезмәттәшлек белән контроль чараларның гомуми саны:

4) хисап чорында үткәрелгән КНМНЫҢ һәр төре буенча үзара хезмәттәшлек итү буенча контроль чаралар саны:

5) хисап чорында дистанцион үзара тәэсир итешү чараларын кулланып үткәрелгән контроль чаралар саны;

6) хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитларның саны;

7) хисап чорында игълан ителгән мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтүләр саны;

8) хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган контроль чаралар саны;

9) хисап чорында административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль чаралар саны;

10) хисап чорында контроль чаралар нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;

11) хисап чорында тикшерү чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

12) хисап чорында прокуратура органнары тарафыннан килештерүдән баш тарткан контроль чаралар үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

13) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контроль объектларының гомуми саны;

14) хисап чоры азагына куркынычның һәр категориясе буенча куркынычлылык категориясенә кертелгән контроль объектларының исәпкә алынган объектлары саны;

15) хисап чоры ахырына контрольдә тотылучы затларның исәпкә алынган саны;

16) хисап чорында контроль чаралар үткәрелгән исәпкә алынган контрольдә тотылучы затлар саны;

17) тикшерү органы тарафыннан карау срогы бозылган шикаятьләрнең хисап чорында саны;

18) контроль органнарның вазыйфаи затларының суд тәртибендә җибәрелгән карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) дәгъвалау турында хисап чорында дәгъва гаризалары саны;

19) контроль органнарының вазыйфаи затларының суд тәртибендә җибәрелгән карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) дәгъвалау турында алар буенча хисап чорында игълан ителгән таләпләрне канәгатьләндерү турында Карар кабул ителгән дәгъва гаризалары саны;

20) муниципаль контрольне оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне тупас бозу белән үткәрелгән һәм аларның нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган һәм (яисә) хисап чорында юкка чыгарылган контроль чаралар саны.